Югары Чура авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 март, 2024 ел №11

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Чура авыл җирлеге Уставы нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 07 апрелендә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарына (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 3700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән:

- Югары Чура авылы юлларына вак таш салу һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;
- Югары Чура авылына насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су суырту манараларын, су саклау зоналарын карап тоту, су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;
- Югары Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу; тракторчы-машинист хезмәтләре;
- Югары Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;
- Югары Чура авылында видеокамералар һәм видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;
- Югары Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылында су суырту манаралары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;
- Югары Чура авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарында (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- *торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;* (Югары Чура авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы юлларына вак таш җәю һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу; тракторчы-машинист хезмәтләре);

- *тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау* (Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау);

- *су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау* (Югары-Чура авылына насослар сатып алу, урнаштыру, артезиан скважиналарын, су саклау зоналарын карап тоту);

(Югары-Чура авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Югары -Чура авылына су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, Чура авылы су суырту манарасы территориясен карап тоту һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- *торак пункт территориясен төзекләндерү* (Югары Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү);

(Югары Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы В.Н. Андреев